Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Ильичевский авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апреле 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Ильичевскийавылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлны ремонтлау, вак таш, асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне (сууткәргеч проектлау һәм төзү)тәэмин итә;-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;

2) 1 пунктның икенче-өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Ильичевскийавылында гражданнар җыены карарына:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлны ремонтлау, вак таш, асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне (сууткәргеч проектлау һәм төзү)тәэмин итә;-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кече Шилнә авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г. Даутов